# КАРАР

**28 ноябрь, 2023 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Сәрдекбаш авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 28 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге Сәрдекбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сәрдекбаш авылында юлларга асфальт җәю, вак таш салып ремонтлау һәм карап тоту; проект-смета документлары һәм проектларга экспертиза; техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Сәрдекбаш авылында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, янгын гидрантларын урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту, янгын инвентаре сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машина сатып алу һәм карап тоту, янгын сүндерү техникасын тотуга чыгымнар; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Сәрдекбаш авылының урам юл челтәрен карап тоту;
- Сәрдекбаш авылы зиратын карап тоту һәм коймалау; зират өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу; проект-смета документларын эшләү;
- Сәрдекбаш авылында урам яктыртуны карап тоту; урам яктырткычлары сатып алу һәм ремонтлау; тимер-бетон терәкләрне монтажлау; проект-смета документларын эшләү;
- Сәрдекбаш авылын төзекләндерү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр; проект-смета документлары;
- Сәрдекбаш авылы суүткәргечен һәм су суырту манарасын карап тоту, артезиан скважинасы өчен насос сатып алу; проект-смета документларын эшләү;

- ял итү зоналарын булдыру , төзекләндерү һәм карап тоту, спорт һәм балалар уен мәйданчыклары һәм инвентарьлар сатып алу; проект-смета документларын эшләү;
- Сәрдекбаш авылы чишмәсен ремонтлау һәм территориясен төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү;
- хоккей мәйданчыгын ремонтлау һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 181 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 96 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 96 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Сәрдекбаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге Сәрдекбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сәрдекбаш авылында юлларга асфальт җәю, вак таш салып ремонтлау һәм карап тоту; проект-смета документлары һәм проектларга экспертиза; техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Сәрдекбаш авылында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, янгын гидрантларын урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту, янгын инвентаре сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машина сатып алу һәм карап тоту, янгын сүндерү техникасын тотуга чыгымнар; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Сәрдекбаш авылының урам юл челтәрен карап тоту;

- Сәрдекбаш авылы зиратын карап тоту һәм коймалау; зират өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу; проект-смета документларын эшләү;
- Сәрдекбаш авылында урам яктыртуны карап тоту; урам яктырткычлары сатып алу һәм ремонтлау; тимер-бетон терәкләрне монтажлау; проект-смета документларын эшләү;
- Сәрдекбаш авылын төзекләндерү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр; проект-смета документлары;
- Сәрдекбаш авылы суүткәргечен һәм су суырту манарасын карап тоту, артезиан скважинасы өчен насос сатып алу; проект-смета документларын эшләү;
- ял итү зоналарын булдыру , төзекләндерү һәм карап тоту, спорт һәм балалар уен мәйданчыклары һәм инвентарьлар сатып алу; проект-смета документларын эшләү;
- Сәрдекбаш авылы чишмәсен ремонтлау һәм территориясен төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү;
- хоккей мәйданчыгын ремонтлау һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Сардекбаш авыл җирлеге башлыгы И.М. Нәбиев